# КАРАР

**30 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

« I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан) кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1650 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Чуллы авылы Хаҗи Закиров, Рәис Ваккасов, Болын урамнары, Тукай тыкрыгы буенча юлларга вак таш җәю;
- зират юлына вак таш җәю һәм зират тукталышы кую;
- проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- җирләү кирәк-яраклары өчен склад бүлмәсе төзү һәм инвентарьлар алу (проект-смета документациясен эшләү);
- Чуллы авылында чишмә территориясен төзекләндерү (чәйнек, вывеска сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Чуллы авылынын Хаҗи Закиров урамы буенча керү (чыгу) юлына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру (сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)»
- Чуллы авылының Хаҗи Закиров урамы буенча агач кисү? »

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 151 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 90 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан) кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1650 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Чуллы авылы Хаҗи Закиров, Рәис Ваккасов, Болын урамнары, Тукай тыкрыгы буенча юлларга вак таш җәю;
- зират юлына вак таш җәю һәм зират тукталышы кую;
- проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- җирләү кирәк-яраклары өчен склад бүлмәсе төзү һәм инвентарьлар алу (проект-смета документациясен эшләү);
- Чуллы авылында чишмә территориясен төзекләндерү (чәйнек, вывеска сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Чуллы авылынын Хаҗи Закиров урамы буенча керү (чыгу) юлына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру (сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Чуллы авылының Хаҗи Закиров урамы буенча агач кисү? »

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Гарипов

ОГРН 1021607753331 ИНН 1623003900